Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы

КАРАР № 4

Зур Мәшләк авылы　　　　　　　　　　　　　　2025 елнын 17 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советының 2023 елның 25 сентябрдәге “Җир салымы турында” гы 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Зур Мәшләк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советының 2023 елның 25 сентябрдәге “Җир салымы турында” гы 11 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 2 пунктның 4 абзацындагы «(эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән гайре)» сүзләрен «,әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән гайре;» сүзләренә алыштырырга;

1.2) 2 пунктның 5 абзацына «, әлеге абзацта күрсәтелгән һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләреннән гайре;» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар үз көчен 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Балык Бистәсе районы Зур Мәшләк авылы, Мәктәп урамы, 13А йорты, Югары Мәшләк авылы, Нариманов урамы, 24а йорты, Бикчурай авылы, Горький урамы, 50а йорты адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-

sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы М.М.Шәмсевәлиев